# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Метрәй авыл җирлегенең Иске Чакмак торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

20 ноябрь 2023 ел.

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2024 елда Мөслим муниципаль районы Метрәй авыл җирлегенең 18 яшькә җиткән һәр теркәлгән кешесеннән 700 (җиде йөз) сум күләмендә үзара салым салу чараларын кертү, 1 һәм 2 төркем инвалидлардан, Әфганстандагы хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылардан, локаль конфликтларда хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылардан, көндезге уку формасындагы студентлардан тыш, алар өчен 350 (өч йөз илле) сум һәм ЛНР һәм ДНРда махсус хәрби операция кысаларында контракт төзегән һәм мобилизацияләнгән гражданнарны шулай ук тормыш иптәше (хатыны), балигъ булган балалары, ә алар булмаганда, әлеге гражданнарның әти-әниләрен салым түләүдән азат итү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү

:1. Урам яктырту челтәрләрен ремонтлау:

- Иске Чакмак авылын яктырту өчен урам яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү, светодиодлы лампаларны сатып алу, урнаштыру.

2. Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын ремонтлау һәм тоту;

- Иске Чакмак авылының Заречная урамы автомобиль юлларын кышкы тоту;
- Иске Чакмак авылының Заречная урамы автомобиль юлларын җәйге тоту;
- Иске Чакмак авылы зираты территориясендә һәм юл буенда үлән чабу.

3. Коймалар төзү, ремонтлау, традицион күмү урыннарын төзекләндерү:

зираттан ККК чыгару;

- үлән чабу (ягулык-майлау материаллары, бензотриммер сатып алу, килешү буенча хезмәт хакы түләү);
- карт агачларны кисү.

4. Һәйкәлләрне ремонтлау, төзү һәм аларга якын территорияне төзекләндерү:

Иске Чакмак авылының Заречная урамындагы Бөек Ватан сугышында һәлак булганнар һәйкәлен төзекләндерү, ремонтлау.

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 57 гражданнар җыенында катнашучы кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 33 кеше, бу 57% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленгән:

«риза» позициясе өчен гражданнар җыенының 33 катнашучысы тавыш бирә; «каршы» позициясе өчен җыенның 0 катнашучысы тавыш бирә.

Бу нигездә, гражданнар җыены:

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Метрәй авыл җирлегенең Иске Чакмак торак пунктында гражданнар җыены узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип танырга

2. 2024 елда Мөслим муниципаль районы Метрәй авыл җирлегенең 18 яшькә җиткән һәр теркәлгән кешесеннән 700 (җиде йөз) сум күләмендә үзара салым салу чараларын кертергә, 1 һәм 2 төркем инвалидлардан, Әфганстандагы хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылардан, локаль конфликтларда хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылардан, көндезге уку формасындагы студентлардан тыш, алар өчен 350 (өч йөз илле) сум һәм ЛНР һәм ДНРда махсус хәрби операция кысаларында контракт төзегән һәм мобилизацияләнгән гражданнарны, шулай ук, тормыш иптәше (хатыны), балигъ булган балалары, ә алар булмаганда, әлеге гражданнарның әти-әниләрен салым түләүдән азат итәргә.

3.Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1. Урам яктырту челтәрләрен ремонтлау:

- Иске Чакмак авылының Заречная урамын яктырту өчен урам яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү, светодиодлы лампаларны сатып алу, урнаштыру.

2. Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын ремонтлау һәм карап тоту.

- Иске Чакмак авылының Заречная урамы автомобиль юлларын кышкы карап тоту.

- Иске Чакмак авылының Заречная урамы автомобиль юлларын җәйге карап тоту.

- Иске Чакмак авылы зираты территориясендә һәм юл буенда үлән чабу.

3. Коймалар төзү, ремонтлау, традицион күмү урыннарын төзекләндерү:

зираттан ККО чыгару;

- үлән чабу (ягулык-майлау материаллары, бензотриммер сатып алу, килешү буенча хезмәт хакы түләү);

- карт агачларны кисү.

4. Һәйкәлләрне ремонтлау, төзү һәм аларга якын территорияне төзекләндерү:

Иске Чакмак авылының Заречная урамында Бөек Ватан сугышында һәлак булганнар һәйкәлен төзекләндерү, ремонтлау.

4. Әлеге карарны ТР Мөслим муниципаль районы Метрәй авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, ТР Мөслим муниципаль районы Метрәй авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм ТР хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

**Метрәй авыл җирлеге Башлыгы** **Шәмгунов И.В.**